КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 23

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 790 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 790 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 февраль, 134 нче; 2023 ел, 23 июнь, 745 нче; 2023 ел, 27 июль, 892 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү тәртибендә:

7.2 пунктның сигезенче абзацында «пролонгацияләү яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6. Индивидуаль программа алты айга кадәр төзелә.»;

7.15 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7.16 пунктта:

икенче абзацта «(индивидуаль программаны пролонгацияләргә кирәк булмаган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыруда катнашучы иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүче оешмалар исемлегендә:

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үсешендә бозылышлар һәм үзенчәлекләр булган балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтү буенча «Звезда» хәйрия фонды (килешү буенча).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин